МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РФ
КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
Институт филологии и межкультурной коммуникации
Кафедра татарской литературы и методики преподавания

Л.И.МИНГАЗОВА

СӘНГАТЬЛЕ УКУ/ ВЫРАЗИТЕЛЬНОЕ ЧТЕНИЕ

Конспект лекций

Казан 2014

Направление: 050302.65 «Родной (татарский) язык и литература; 050100.62 «Педагогическое образование» Родной (татарский) язык и литература.

Учебные планы: Учитель родного языка, литературы и английского языка (не предусмотрено) (очное, 2012); Образование в области родного (татарского) языка и литературы (очное, 2013)

Дисциплина: Выразительное чтение (бакалавриат, 1-2 курс, 2-3 семестры, очное обучение)

Количество часов: 36 (в том числе: лекции - 10, практические занятия - 26, лабораторные работы – 0) , форма контроля: зачет

Аннотация: Данный курс раскрывает основные направления приобретения студентами навыка анализа литературного произведения, необходимого для выразительного чтения, учатся художественно исполнять произведения. Курс раскрывает необходимость использовать в выразительном чтении правил техники речи и орфоэпии, интонации, логики чтения, силы и тембра голоса, темп речи, а также жеста и мимики. Выразительное чтение активизирует художественное восприятие литературного произведения, поскольку такое восприятие осуществляется в процессе исполнительского анализа, требующего достаточно глубокого и творческого освоения явлений литературы.

Темы: 1. Кереш. Фән буларак сәнгатьле уку. 2. Сәнгатьле укуның нигезе. Интонация. 3. Басым. Тыныш (Пауза). Сөйләм тизлеге. 4. Инверсия. Тавыш. Логик перспектива. 5. Сөйләү техникасы. Сулыш.

Ключевые слова: выразительная триада, техника речи, дыхание, голос, дикция, техника и логика речи, эмоционально-образная выразительность, жест, мимика, поза, партитура, партитурные знаки

Автор курса: Мингазова Ляйля Ихсановна Доктор филологических наук. Доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания
email: Leila69@inbox.ru :8-90-476-38-701

Дата начала эксплуатации: 01.12. 2014 (ориентировочно)

Язык интерфейса: татарский

URL электронного курса в MOODLE:
http://tulpar.kfu.ru/course/view.php?id=2004

ЭЧТӘЛЕК

Тема 1.
ЛЕКЦИЯ 1. КЕРЕШ. ФӘН БУЛАРАК СӘНГАТЬЛЕ УКУ........................4
КЕРЕШ.. 5
ФӘН БУЛАРАК СӘНГАТЬЛЕ УКУ...6

Тема 2.
ЛЕКЦИЯ 2. СӘНГАТЬЛЕ УКУНЫҢ НИГЕЗЕ. ИНТОНАЦИЯ................8
СӘНГАТЬЛЕ УКУНЫҢ НИГЕЗЕ..10
ИНТОНАЦИЯ 10

ЛЕКЦИЯ 3. БАСЫМ. ТЫНЫШ (ПАУЗА). СӨЙЛӘМ ТИЗЛЕГЕ
БАСЫМ..13
ТЫНЫШ (ПАУЗА)...14
СӨЙЛӘМ ТИЗЛЕГЕ..17

ЛЕКЦИЯ 4. ИНВЕРСИЯ, ТАВЫШ, ЛОГИК ПЕРСПЕКТИВА.. 18
ИНВЕРСИЯ..20
ЛОГИК ПЕРСПЕКТИВА...20
ТАВЫШ..21

ЛЕКЦИЯ 5. СӨЙЛӘҮ ТЕХНИКАСЫ..22
СӨЙЛӘҮ ТЕХНИКАСЫ..24
ТАВЫШНЫ САКЛАУ ҺӘМ ДӨРЕС СУЛЫШ АЛУ ӨЧЕН
КҮНЕГҮЛӘР...25

ГЛОССАРИЙ...28
ӘДӘБИЯТ 30
МӨСТӘКЫЙЛЬ ЭШ ӨЧЕН БИРЕМНӘР ҺӘМ
КОНТРОЛЬ СОРАУЛАР..31
ГАМӘЛИ СОРАУЛАР..32
ЗАЧЕТ ӨЧЕН СОРАУЛАР..32

Тема 1.

ЛЕКЦИЯ 1. КЕРЕШ. ФӘН БУЛАРАК СӘНГАТЬЛЕ УКУ

Аннотация. Лекциядә курс алдына куелган төп максат һәм бурычлар, фәннең эчтәлеген үзләштерү дәрәҗәсенә таләпләр карала. Сәнгатьле уку методикасының тарихына күзәтү эшләнә.

Сәнгатьле уку курсының педагогик, психологик, методик мәсәләләр белән үзара бәйләнгән булуы һәм аларны белүнең мәктәпләрдә эш өчен мәҗбүрияте ассызыклана.

Ключевые слова: Сәнгатьле уку, бурыч, максатлар, тарих.

Методик рекомендацияләр: Дәрестә теоритик мәсьәләләр карала, курсның әһәмияте ассызыклана. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә.

Төп әдәбият

1. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: Таткитнәшр., 1988. - 86 б.
2. Галимуллин Ф.Г. Мәктәптә сәнгатьле уку: Студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: КДПИ, 1984. – 101 б.
3. Буяльский Б.А. Искусство выразительного чтения / Б.А. Буяльский. - М., 2006.
4. Майман Р.Р. Выразительное чтение. Практикум / Р.Р. Майман. - М., 2000.

Өстәмә әдәбият

1. Аксенов В.Н. Искусство художественного слова. - М., 2005.
2. Найденов Б.С. Выразительность речи и чтения. - М., 2000.
3. Рыбникова М.А. Очерки по методике выразительного чтения. - М., 2005.

Интернет ресурслар

http://studysphere.ru/work.php?id=339 - http://studysphere.ru/work.php?id=339

http://www.detskiysad.ru/ped/virazhenie.html - http://www.detskiysad.ru/ped/virazhenie.html

http://www.tatarstan.ru/books/ - http://www.tatarstan.ru/books/

Книгафонд - http://libress.kpfu.ru/wpad.dat

Книгафонд - www. knigafond.ru

Глоссарий

Анализ (бүлгәләү) – бербөтенне өлешләргә таркатып, төп кисәк-компонентларны аерып чыгаручф һәм алар арасындагы бәйләнешләрне табучы фәнни ысул.

Антитеза – капма-каршы төшенчәләрне, факт, образларны махсус рәвештә капма-каршы кую.

Аргументы – лекция уку барышында лектор тарафыннан ышандыру өчен кулланылган психологик, логик и фактик дәлилләр (идея, чакыру, мисал, фактлар һ.б.) һәм аларны куллану ысуллары.

Нәтиҗә – лекция азагында сөйләгәннәрне йомгаклап кую, нәтиҗә ясау.

Интонация – мәгънәви, синтаксик, эмоциональ-экспрессив функция башкаручы ритмлы-мелодик сөйләм сыйфаты. Ул үз эченә түбәндәге элементларны ала: мелодия, темп, ритм, сөйләм көче, тавыш тембры, шулай ук мәгънәви, фраза, логик басым һ.б.

Лекциядә каралган мәсьәләләр:

1. Сәнгатьле уку курсының бурычлары һәм максатлары
2. Сәнгатьле укуның нигезләре
3. Сәнгатьле уку курсының әһәмияте.

Сәнгатьле уку - кәгазьгә төшерелгән әдәби әсәрне җанлы сөйләмгә әверелдерүне, тыңлаучыга әйтергә теләгән фикерне үтемле, тәэсирле итеп җиткерүне күздә тота.

Сәнгатьле уку өчен:

1. Әсәрне дөрес аңлау мәҗбүри;

2. Әсәрдә яки шигырьдә әйтергә теләгән хәлләрне, кичерешләрне күзаллау, кичерү бик мөһим шарт.

3. Мимика, хәрәкәт фикерне укучыга җиткерүдә зур урын тота.

Сәнгатьле уку тормыштагы сөйләмгә нигезләнә. Мөмкин кадәр гади, күңелгә үтеп керерлек итеп сөйләү сәнгатьлелекне тәэмин итә. Әмма

сәнгатьле уку тормыштагыча гына сөйләү түгел. Чөнки әдәбият, поэзия дөньясы – үзенчәлекле. Биредә сөйләм, хисләр аерылып тора.

Танылган сүз остасы В. Н. Аксенов болай дип яза: «Сәнгатьле укуның нигезе, бөтен мәгънәсе дикциядә дә, тавышта да, хәтта фразаны яки әсәрнең өзеген грамоталы тикшерүдә дә түгел, ә бәлки әсәрне дөрес трактовкалауда, ягъни автор идеясен аңлап, аны үзеңнең актив мөнәсәбәтең белән сугару, материалны дөрес анализлау һәм дөрес бәяләү нәтиҗәсендә кирәкле интонацияне табу, шуның аркылы үзеңнең иҗади бурычыңны ачыклауда». Димәк, эчтәлек форманы билгели дигән мәгълүм хакыйкать бу юлы да үз көчендә кала.

Әсәрне кулга алгач, төп ике сорау куела:

1. Бу әсәр белән нәрсә әйтергә телибез?

2. Фикерне ничек үтемлерәк итеп җиткерергә? (Әсәрдәге хис-вакыйганы кичерү мәҗбүри, шул очракта гына тиешле нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Әмма, һәр кеше теге яки бу вакыйганы үзенчә кичерә һәм җиткерә дә).

Татар халкының билгеле сүз осталары: Айрат Арсланов, Әзәл Яһудин, Фәйзи Юсупов, Илдус Сафин, Рәшит Сабиров, Зөһрә Шакирҗанова һ.б.

Татарлар күп гасырлар буена әдәбиятлы һәм китаплы халык. Татар телендә борын-борыннан берсеннән-берсе гүзәл әдәби әсәрләр иҗат ителеп киленгән. Бигрәк тә шигъри әсәрләрнең аһәңле, ягымлы һәм төрле сурәтләргә бай теленә без сокланып туймыйбыз. Чәчмә һәм драма әсәрләре дә телебезнең киң мөмкинлекләре ярдәмендә шигърият дәрәҗәсенә күтәрелә баралар. Татар теленең сыгылмалылыгын, матур яңгырашын тәэмин итүдә дини әдәбиятның, Көнчыгыш сүз сәнгате әсәрләренең тәэсире әйтеп бетергесез көчле булган. Телебез халыклар арасында аралашу коралы буларак та даими файдаланып киленгән. Бу телдә фәлсәфи, тарихи, хокукый һәм фәннең башка өлкәләренә караган хезмәтләр дә язылган. Күрәбез, язма тел мәдәниятебез шактый югары дәрәҗәгә ирешкән.

Әмма кешеләр телне иң әүвәл сөйләмдә, бер-берләре белән гадәти аралашуда кулланалар. Кызганычка каршы, нәкъ менә шушы өлкәдә – җанлы сөйләмдә телебезнең матур яңгырашын саклауга, аның хисси, тасвирый һәм тәэсирлелек көчен арттыруга җитәрлек игътибар бирелми. Еллар узган саен, сөйләм бары тик нәрсәне дә булса хәбәр итү чарасы булып кына кала бара. Әлбәттә, бу телнең ярлылануына китерә.

Мәктәптә балаларны сөйләмнең мәгънәви ягына игътибарлы булырга өйрәтү белән бергә, аларның бер үк вакытта әйтелгәннәргә бәрабәр хис-кичерешләрен, мөнәсәбәтләрен дә җиткерергә күнектерү – әдәбият һәм тел укытучыларының төп бурычларыннан берсе. Булачак укытучы моны эшләүнең ысуллары белән яхшы коралланырга тиеш.

Матур һәм сәнгатьле итеп уку бик катлаулы эш. Ул махсус әзерлек, тиешле теоретик белем һәм гамәли күнекмәләр булдыруны таләп итә. Хезмәте сөйләм мәдәнияте белән бәйләнмәгән башка һөнәр кешеләре өчен матур итеп сөйләү, сәнгатьле уку күнекмәләренә ия булу, ихтимал, мәҗбүри дә түгелдер. Әмма укытучы өчен сәнгатьле итеп сөйли һәм укый белү бик мөһим, чөнки ул телне укучыга белем һәм тәрбия бирү максатында файдалана, туган телебезнең матурлыгын күрсәтеп бирә, аңа карата мәхәббәт тәрбияли. Тел аның төп эш коралы. Укытучы балага һәръяклап үрнәк булырга тиеш. Чөнки бала укытучыдагы һәр нәрсәне үзенә сеңдерә, шул исәптән, аның сөйләме дә игътибар үзәгендә. Шуңа күрә, укытучы үзе дөрес әдәби тел нормалары белән сөйләргә, укучылар телендә булган аерым кимчелекләрне билгели һәм аларны бетерү юлларын белергә, теләсә кайсы матур әдәбият әсәрен сәнгатьле итеп укырга һәм моны эшләүнең ысулларын, юлларын, алымнарын үзләштереп, укучыны да шуңа өйрәтергә бурычлы.

Сәнгатьле уку курсын үткәндә түбәндәге максатларга ирешү күздә тотыла:

- сәнгатьле укуның тарихыннан һәм теориясеннән мәгълүмат бирү;
- мәктәп баларын сәнгатьле укырга өйрәтүнең методлары һәм алымнары белән коралландыру;

- булачак укытучыларның сәнгатьле уку осталыгын камилләштерү;
- сәнгатьле уку буенча төп фәнни-методик хезмәтләр белән таныштыру, аларда тәкъдим ителгәннәрне гамәли кулланырга өйрәтү;
- сөйләм аппараты турында мәгълүмат бирү һәм аннан дөрес файдалану күнекмәләрен булдыру;
- әдәби текст белән эшләргә өйрәтү, сәнгатьле укылырга тиешле әсәрнең партитурасын төзү һәм шуның буенча дөрес итеп уку күнекмәләре тәрбияләү.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сәнгатьле укуның туган тел һәм әдәбиятны укытудагы әһәмиятен нәрсәдә күрәсез?
2. Укучының үз сөйләмен аһәңле, үтемле итеп әверелдерүдә сәнгатьле укуның ярдәме ниләрдән гыйбарәт?
3. Әдәби әсәр текстын үз сүзең итеп әверелдерү дигәндә, ниләрне күздә тотабыз һәм моны ничек эшлибез?
4. Сөйләм культурасы белән сәнгатьле уку арасында нинди аерма бар?

Тема 2.
ЛЕКЦИЯ 2. СӘНГАТЬЛЕ УКУНЫҢ НИГЕЗЕ. ИНТОНАЦИЯ.

Аннотация. Лекция барышында сүз сәнгате һәм аның үзенчәлекләре, татар мәктәпләрендә сәнгатьле уку методикасының инкыйлабка кадәр һәм аннан соңгы елларда үстерелеше, бу өлкәдә хезмәт күрсәткән галимнәр һәм методистлар турында сүз бара. Сәнгатьле уку өчен аларның әһәмияте ассызыклана. Интонация төшенчәсенә бәя бирелә.

Ключевые слова: Сәнгатьле уку, галимнәр һәм методистлар, сөйләм аппараты, интонация.

Методик рекомендацияләр: Дәрестә теоритик мәсьәләләр карала, сәнгатьле укуның нигезе, интонация төшенчәсе ассызыклана. Иҗади эш өчен студентларга, үтелгән тема буенча эш, презентация әзерләү тәкъдим ителә. Текстлар әзерләү эше башлана.

Төп әдәбият

5. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: Таткитнәшр., 1988. - 86 б.
6. Галимуллин Ф.Г. Мәктәптә сәнгатьле уку: Студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: КДПИ, 1984. – 101 б.
7. Буяльский Б.А. Искусство выразительного чтения / Б.А. Буяльский. - М., 2006.
8. Майман Р.Р. Выразительное чтение. Практикум / Р.Р. Майман. - М., 2000.

Өстәмә әдәбият

4. Аксенов В.Н. Искусство художественного слова. - М., 2005.
5. Найденов Б.С. Выразительность речи и чтения. - М., 2000.
6. Рыбникова М.А. Очерки по методике выразительного чтения. - М., 2005.

Интернет ресурслар

http://studysphere.ru/work.php?id=339 - http://studysphere.ru/work.php?id=339

http://www.detskiysad.ru/ped/virazhenie.html - http://www.detskiysad.ru/ped/virazhenie.html

http://www.tatarstan.ru/books/ - http://www.tatarstan.ru/books/

Книгафонд - http://libress.kpfu.ru/wpad.dat
Книгафонд - www. knigafond.ru

Глоссарий

Интонация – мәгънәви, синтаксик, эмоциональ-экспрессив функция башкаручы ритмлы-мелодик сөйләм сыйфаты. Ул үз эченә түбәндәге элементларны ала: мелодия, темп, ритм, сөйләм көче, тавыш тембры, шулай ук мәгънәви, фраза, логик басым һ.б.

Интонацион шигырь – буыннар төшеп калу яки өстәлү сәбәпле, төрле ритмик үлчәмдә язылган шигырь формасы.

Комментария – лектор тарафыннан теге яки бу мәсьәләгә ачыклык кертү.

Конкретлаштыру – композицион-стилистик алым, теге яки бу мәсьәләгә ачыклык кертү өчен аны детальләштерү.

Лекция-беседа – тыңлап утыручыларның да актив катнашуын таләп иткән чыгыш-лекция .

Лекциядә каралган мәсьәләләр:

1. Сүз сәнгате һәм аның үзенчәлекләре. Татар мәктәпләрендә сәнгатьле уку методикасының инкыйлабка кадәр һәм аннан соңгы елларда үстерелеше, бу өлкәдә хезмәт күрсәткән галимнәр һәм методистлар. Сәнгатьле укый белүнең укытучы өчен әһәмияте, бүгенге көндә мәктәпләребездә аны укытуның торышы.
2.Интонация турында төшенчә. Тавыш хәрәкәте ягыннан интонация төрлелеге һәм эчтәлек ягыннан интонацияләр төрлелеге.
3. Басымның әһәмияте һәм төрләре. Аларның шартлы билгеләре. Татар телендә басымнарның урыны. Сүз басымы. Фраза басымы. Җөмләдәге басым һ.б.
4. Тыныш (пауза) турында белешмә. Текстның фразаларга бүленүе. Тынышларның әһәмияте, төрләре, аларның бурычлары. Тынышның башка төрләре: искә төшерү, күтәрү һ.б.
5. Сөйләм тизлеге. Тизлекнең эчтәлектән, әсәрнең сюжет үстерелешеннән, төзелешеннән килеп чыгуы. Автор фикерен җиткерүдә сөйләм темпының роле. Әсәрнең жанры һәм аны укуның тизлеге арасындагы бәйләнеш.

Сүз сәнгате һәм аның үзенчәлекләре. Татар мәктәпләрендә сәнгатьле уку методикасының инкыйлабка кадәр һәм аннан соңгы елларда үстерелеше, бу өлкәдә хезмәт күрсәткән галимнәр һәм методистлар. Сәнгатьле укый белүнең укытучы өчен әһәмияте, бүгенге көндә мәктәпләребездә аны укытуның торышы. Сәнгатьле укый белүнең әдәбият укытучысы өчен кирәклеге турында Г.Бәширов, Г.Әпсәләмов. Сөйләм интонациясе. Укуны кабул итү үзенчәлекләре.

Интонация — латин сүзе, көчле әйтү мәгънәсендә. Сөйләмнең тонын, аның ритмик-мелодик ягын, тавыш күтәрелү-төшүнең чиратлашуын аңлата. Сөйләмнең интонациясе дигәндә хисләрне, сөйләүченең сөйләм предметына мөнәсәбәтен белдерүче сүзләрне әйтүнең тоны һәм рәвеше күздә тотыла. Интонациянең төп функциясе текстның мәгънәсен һәм аңа салынган мөнәсәбәтне белдерү. Интонация, ягъни тавышның сөйләмдәге төрлечә хәрәкәте (күтәрелүе, төшүе, аерым урында көчлерәк яки көчсезрәк, сузыбрак яки кыска итеп, тиз генә әйтелүе, паузалар ясау һ.б.) җөмләдә кирәкле

мәгънә бирү өчен хезмәт итә. Басым, пауза, сөйләм темпы, тавыш көче — барысы да интонациянең элементлары, алар бөтенесе бергә интонацияне тәшкил итәләр.

Бер үк әсәр төрле башкаручы тарафыннан төрлечә тәкъдим ителергә мөмкин. Бу ягы бары тик сәнгатьле укучының тормыш тәҗрибәсенә, эстетик зәвыгына, хис байлыгына, табигый мөмкинлекләренә бәйле.

Интонация, текстның эчтәлегенә бәйле рәвештә, күп төрле булырга мөмкин: хәбәр итү, раслау, боеру, өндәү, үтенү, ялвару, астыртын көлү, усал көлү, яшь аралаш көлү, шик ләнү, инкарь итү, фараз кылу һәм башкалар. Бер җөмләдә без нәрсәне дә булса расласак, икенчесендә аны юкка чыгаруыбыз мөмкин. Мисаллар.

Интонация, тавыш хәрәкәтенә карап, берничә төргә бүленә. М.З.Зәкиев аларны түбәндәгечә билгели: тулы интонация, күтәрелүче интонация, катнаш интонация.

1. Тулы интонация, ягъни күтәрелү өлеше, югары ноктасы һәм төшү өлеше булган интонация. (Мисаллар).

2. Күтәрелүче интонация, әкренләп күтәрелеп бара һәм үзенең иң югары ноктасында кинәт туктап кала торган интонация. (Мисаллар).

3. Төшүче интонация, ягъни үзенең югары ноктасыннан башланып, әкренләп төшеп баручы интонация. (Мисаллар).

4. Катнаш интонация, тавыш хәрәкәтенең биредә аеруча актив булуы күзәтелә. (Мисаллар).

Сораулар һәм биремнәр

1.Сүзне әйтү максаты белән тиешле интонация арасындагы бәйләнешне ниләрдә күрәбез?

2.Интонациянең төгәл яңгыравының нигезендәниләр ята?

3.“Тел төбен” (подтекстны) дөрес билгеләү белән тиешле интонацияне табудагы бәйләнешләр турында ниләр әйтә аласыз?

4.“Тел төбен” (подтекстны) белдерү чараларыннан дөрес файдалануның әһәмиятен сезниләрдә күрәсез?

Тема 2.
ЛЕКЦИЯ 3. БАСЫМ. ТЫНЫШ (ПАУЗА). СӨЙЛӘМ ТИЗЛЕГЕ.

Аннотация. Лекция барышында аһәңле укуның әдәби әсәрнең фикри–сәнгатьчә һәм форма үзенчәлекләрен билгеләүдәге роле ачыклана. Сәнгатьле укуга әзерләнгәндә әдәби тәфтишләү (анализ) алымнары, образларны хыялда гәүдәләндереп күз алдына китерү, автор сурәтләгәннәргә хисси мөнәсәбәт уяту, әсәрне уку өчен бурычлар билгеләү, тел төбен ачу һәм аның гомуми әдәби тәфтишләү белән табигый бәйләнеше ачыклана. Интонация, басымның әһәмияте һәм төрләре, текстның фразаларга бүленүе турында белем бирелә.

Ключевые слова: Сәнгатьле уку, басым, аның төрләре, пауза, текстның фразаларга бүлү.

Методик рекомендацияләр: Дәрестә теоритик мәсьәләләр карала, басым, аның төрләре, пауза, текстның фразаларга бүлү, сөйләм тизлеге төшенчәләре ассызыклана. Иҗади эш өчен студентларга, үтелгән тема буенча эш, презентация әзерләү тәкъдим ителә. Текстлар әзерләү эше тикшерелә.

Төп әдәбият

9. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: Таткитнәшр., 1988. - 86 б.
10. Галимуллин Ф.Г. Мәктәптә сәнгатьле уку: Студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: КДПИ, 1984. – 101 б.
11. Буяльский Б.А. Искусство выразительного чтения / Б.А. Буяльский. - М., 2006.
12. Майман Р.Р. Выразительное чтение. Практикум / Р.Р. Майман. - М., 2000.

Өстәмә әдәбият

7. Аксенов В.Н. Искусство художественного слова. - М., 2005.
8. Найденов Б.С. Выразительность речи и чтения. - М., 2000.
9. Рыбникова М.А. Очерки по методике выразительного чтения. - М., 2005.

Интернет ресурслар

http://studysphere.ru/work.php?id=339 - http://studysphere.ru/work.php?id=339

http://www.detskiysad.ru/ped/virazhenie.html - http://www.detskiysad.ru/ped/virazhenie.html

http://www.tatarstan.ru/books/ - http://www.tatarstan.ru/books/

Книгафонд - http://libress.kpfu.ru/wpad.dat
Книгафонд - www. knigafond.ru

Глоссарий

Логик пауза – әһәмиятле пауза, текстны төгәл, дөрес итеп уку өчен, мәгънәле кисәкләрне аерып чыгару өчен кулланыла.

Пауза – физиологик, грамматик, психологик яки логик факторлар белән бәйле рәвештә сөйләмдә туктап тору.

Сөйләм тембры – авазлар бизәге.

Сөйләм темпы – сөйләм барышында авазларны, сүзләрне, җөмләләрне әйтү тизлеге.

Жест – кешенең сөйләме, аралашуы барышында гомум моториканың (хәрәкәтнең) теге яки бу күләмдә чагылышы. Мисал өчен, мимика (бит-йөз мускулларының хәрәкәте), пантомимика – (бөтен гәүдәнең хәрәкәте) һәм жестикуляция (кул хәрәкәте).

Басым - сөйләмдә оештыру үзәге, астекстны белдерергә ярдәм итә торган әһәмиятле чараларның берсе. Сүздә ул нинди дә булса сузык авазга төшкән басым, фразада, җөмләдә басым төшкән сүз. Барлык башка авазлар яки сүзләр басым төшкән сүз тирәсенә тупланып әйтеләләр. Басым төшкән иҗектән ераклашкан саен, сузык аваз кыскарак әйтелә һәм үзенә хас яңгырашын җуя бара. Басым төшкән сүзләр дә басымсыз сүзләргә караганда тулы, ачык әйтелүләре белән аерылып торалар. Басым, гадәттә, җөмләдәге әһәмиятле сүзгә төшә. Димәк, басым төшкән сүзне дөрес табу текстны аңлау белән бик нык бәйле икән.

Басым ике төрле була: мәгънәви басым һәм тойгы басымы. Исемнәреннән үк аңлашылганча, **мәгънәви** (логик) басым фикернең асыл мәгънәсен, **тойгы** басымы исә аңа салынган хис-кичерешне белдерү функцияләрен башкара.

Сөйләм билгеле бер ритмик буыннардан тора. Мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән берничә сүзне бер басым астына алып әйтүне - **сөйләм такты** дип атыйлар. Мәгънәви басым иң әүвәл шушы сөйләм тактының үзәге буларак әһәмиятле.

Басымнар ике төрле була дидек: мәгънәви һәм тойгылы. Ләкин алар бер үк әйбернең ике ягы кебек. Мәгънәви басым белән тойгы басымы тавышта бер үк вакытта барлыкка килә, ник дигәндә, башта басым белән фикерне әйтеп, аның артыннан тойгыны белдереп булмый, болар икесе бергә эшләнә. Тик эш шунда — кайбер текстны укыганда сөйләүче алдында мәгънәне белдерү беренче планга чыкса, икенчесен укыганда хис-кичерешне бирү өстенлек алырга мөмкин. Басымнарның ике төренә дә бер үк дәрәҗәдә игътибар итәргә кирәк очраклар да еш була.

Басым төшкән сүзләрне билгеләү өчен шартлы билгеләр кулланыла. Мәгънәви басым төшкән сүз астына горизонталь туры сызык, тойгылы басым төшкән сүз астына горизонталь дулкынлы сызык сызыла. Басым төшкән сүзләр тавыш, хис көче ягыннан барысы да бертөрле дәрәҗәдә генә аерып чыгарылмый. Шуңа күрә, шартлы рәвештә, басымны бүлеп чыгаруның өч дәрәҗәсен билгелиләр.

Мәгънәви басым Тойгы басымы

1 дәрәҗә <u>……………</u>

2 дәрәҗә <u>……………</u>

3 дәрәҗә <u>……………</u>

Күп очракта бер үк сүзне һәм мәгънәви, һәм тойгылы басым белән әйтергә туры килә. Андый вакытта бу сүзләрнең астына икесенең дә шартлы билгесе бергә куела.

1 дәрәҗә <u>……………</u>

2 дәрәҗә ……………

3 дәрәҗә ……………

Гадәттә, басым алган сүз тавышны көчәйтү юлы белән әйтелә. Әмма бу бердәнбер чара түгел. Басым төшкән сүзләрнең кайберләрең, киресенчә, тавыш көчен кимету юлы белән әйтергә мөмкин. Болай иткәндә дә ул җөмләдәге башка сүзләрдән аерылып торачак, аңа тыңлаучы игътибар итәчәк һәм сөйләм ягымлы булып кабул ителәчәк. Кайбер очракларда басым төшкән сүзне иҗекләп әйтү юлы белән дә аерып чыгарырга ярый.

Йомгак ясап әйткәндә, басым астекстны, андагы мәгънәви-эмоциональ эчтәлекне тыңлаучыга җиткерүдә бик әһәмиятле чара. Аны дөрес билгеләү, аерып чыгару автор әйтергә теләгән төп фикерне дөрес аңлауга бәйле.

Астекстны белдерүнең төп чараларыннан булган паузаның сәнгатьле укуда роле бик зур. Пауза - латин һәм грек телләреннән тәрҗемә иткәндә бүленеп тору, вакытлыча туктап тору мәгънәсен белдерә. Пауза - сүзләр арасындагы мәгънә бәйләнешен белдерә.

Ике пауза арасына урнашкан сүз яки сүзләр төркемен сөйләм такты дип атыйбыз. Сөйләм тактын бер сүз дә, берничә сүз бергә берләшеп тә тәшкил итәргә мөмкин. Паузаларның дәвамлылыгы да төрлечә. Сизелер-сизелмәс кенә ясалганнары да бар, шактый озыннары да очрый. Сүзләр бер-берсенә мәгънә ягыннан никадәр якын булсалар, алар арасында пауза да кыска була. Киресенчә, мәгънә бәйләнеше кимегән саен, паузалар да озынрак була. Текстның гомуми мәгънәсен һәм аерым сөйләм тактлары белдергән мәгънәне ачыклау сәнгатьле укырга әзерлекнең мөһим этабы булып әверелә.

Паузалар берьюлы ике функция үтиләр: сөйләм тактларын бер-берсеннән аералар һәм контекстны берләштерәләр. Паузаны дөрес яки ялгыш куюдан мәгънә бик нык үзгәрергә мөмкин. М. Галәүнең «Канлы тамгалар» эпопеясындагы бер җөмләне алып, төрле урында пауза ясаудан һәр очракта яңа мәгънә килеп чыгуын күзәтик.

Сәлим карт, / кызы белән улын ияртеп, /казармага таба китеп барды.

Сәлим, | карт кызы белән улын ияртеп, | казармага таба китеп барды.

Сәлим карт кызы белән, | улын ияртеп, | казармага таба китеп барды.

Паузалар шулай ук ике зур төркемгә бүленәләр: логик пауза һәм тойгылы пауза. Логик (мәгънәви) паузаның төп функциясе текcттагы мәгънәне дөрес җиткерү. Паузаны дөрес куймаганлыктан, мәгънә үзгәрү очраклары алдагы мисалларда күрсәтелде инде. Логик паузаның тагын берничә вазифасы бар. Аларның аеруча еш очрый торганнары түбәндәгеләр:

1. Аңлау өчен кыенрак, кереш җөмләне үз эченә алган текстларда мәгънә ачыклыгын тәэмин итү максатында куллану. (Мисаллар).

2. Паузаларның ритмик функциясе дә була. (Мисаллар).

Строфа юлларындагы иҗекләр саны тигез түгел. Ләкин укыганда «аксау» сизмибез, чөнки мондый тигезсезлек пауза ясау нәтиҗәсендә юкка чыга.

3. Логик пауза шигъри әсәрләрдә тагын бер функция башкара. Шигырь юлы уртасында ук, берәр фикер төгәлләнеп, икенче яңа фикер башланырга мөмкин. Әмма шигырь таләпләреннән чыгып, һәр юл азагында тукталыш ясала. Әйтергә кирәк, мондый пауза вакытында тавышта фикернең төгәлләнмәгәнен, дәвам итәчәген белдергән күтәрелмә интонация сиземләнергә тиеш. Моны тотып ала белү һәм тиешенчә уку сәнгатьле укучы өчен мәҗбүри. (Мисаллар).

Мәгънәви пауза белән бергә сәнгатьле укуда тойгылы пауза да гаять әһәмиятле. Икенче төрле аны психологик пауза дип тә атыйлар. Чыннан да, сөйләшкән вакытта кеше төрле психологик халәттә булырга мөмкин. Ләкин шул психологик халәтне мимикага, кул хәрәкәтләренә, интонациягә чыгару, әңгәмәдәшенә сиздерү дәрәҗәсе һәр кешедә төрлечә була. (Мисаллар).

Текстларда паузаның ике төре дә — һәм мәгънәви, һәм тойгылысы да кулланылды. Мәгънәви паузаның **шартлы** билгесе |, тойгылы паузаныкы ;. Пауза дәвамлылык **ягыннан да** төрлечә була. Гадәттә, бу яктан аны өч дәрәҗәгә **бүлеп** йөртәләр.

Мәгънәви пауза Беренче дәрәҗә / **Тойгылы пауза**

Икенче дәрәҗә //

Өченче дәрәҗә ///

Сүз сәнгате остасы Г.В.Артоболевский тойгылы паузаның түбәндәге төрләрен билгели:

1. Искә төшерү паузасы. (Мисаллар).

2. Нәрсәнедер әйтеп бетермәү паузасы.

3. Киеренкелек паузасы. Сөйләмдә туктап алу тынлаучыны сагайта, аны аеруча әһәмиятле фикерне кабул итәргә хәзерли. (Мисаллар).

4. Паузаның физиологик төре дә бар. Ул сөйләүче кешенең шушы вакыттагы физик халәтен белдерүгә хезмәт итә. (Мисаллар).

Паузалар ясау зур осталык сорый. Сәнгатьле укучы пауза ясаганда, тыңлаучы аның белән бергә ул кичергәннәрне хис итәргә тиеш. Димәк, пауза ул тик туктап тору түгел, бәлки фикер, кичерешнең табигый дәвам итүе. Бары тик үзең тирән кичергәндә генә, тыңлаучыны да хисләрең артыннан ияртергә мөмкин.

<u>Сөйләү темпы.</u> Тормышта төрлечә сөйләшүчеләр белән очрашабыз. Бу барыннан да элек кешенең нинди характер иясе булуыннан килә. Югары нерв эшчәнлеге типларының сангвиник, флегматик, холерик, меланхолик кебек төрләргә бүленүе сөйләмгә дә тулысынча тәэсир итә. Кайсы кеше бик салмак сөйли. Андый кешенең сүзен авызыннан тартып алырдай буласың. Сөйләшү фикерләү үзенчәлеге белән бәйле. Димәк, бу кешедә фикерләү процессы да салмак бара. Кеше, бик кызу хәрәкәтләнеп, салмак сөйләшсә, бик сәер булыр иде, әлбәттә. Шул ук вакытта тиз-тиз сөйләшүчеләр дә очрый. Алар эш-хәрәкәтләрендә дә кызуланалар, ашыгалар. Мондый кешеләр сүзләренең аныклыгы, төгәл яңгыравы турында кайгыртмыйлар. Шул сәбәпле аларның әйткән сүзләрен кабат-кабат сорап төшенергә туры килә. Ә кеше сәнгатьле укыган вакытта, берәр сүзне аңламый калсаң, нәрсә әйттегез, дип кабат сорап булмый.

Тормыштагы кебек үк, сәнгатьле укуда да нигездә төрле сөйләм темпы белән эш итәбез.

1. Тиз (кызу).

2. Уртача.

3. Салмак.

Шулай да уртача сөйләм темпының ешрак кулланылуын әтергә кирәк. Ә. Нигъмәтуллин «Сәнгатьле укырга өйрәник» дигән кулланмасында темпның башка тизлекләрен дә күрсәтеп үтә.

1. Бик акрын. 4. Йөгерек.

2. Акрын. 5. Кызу.

3. Талгын. 6. Бик кызу.

Чынбарлыкта боларның һәммәсе дә бар. Шуңа күрә мондый бүленеш эш итү өчен тагын да җайлырак булуы белән аерылып тора.

Әсәрне укырга алынгач, аның идеясен, сурәтләү чараларын, төзелешен билгеләгән вакытта сөйләү темпын да ачыкларга туры килә. Ләкин сөйләү темпын, бу әсәрне шушы тизлектә укыйм әле дип, ясалма рәвештә сайлап булмый. Ул шулай ук әсәрнең эчтәлегеннән, рухыннан, төзелешеннән табигый килеп чыгарга тиеш. М.Җәлилнең «Җырларым» шигырен салмак итеп тә, бик тиз дә укый алмыйбыз. Биредә үзәктә уртача темп торырга тиеш.

Ләкин барлык әсәрне башыннан ахырына кадәр бер үк темп белән укырга кирәк икән дигән караш булмаска тиеш. «Җырларым», «Күңелем Ленин белән сөйләшә» әсәрләрендә дә темп төрлелеге китереп чыгарырдай, ягъни шуны сорап торган урыннар бар. Күпчелек әсәрләрне укыганда сөйләм темпының динамикалы булуы таләп ителә. Бу — вакыйгалар, хисләр алмашуыннан, әсәрнең эчке ихтыяҗларыннан килеп чыга. Менә фронтовик шагыйрь Фатих Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасын укыганда темпның хәрәкәтен күзәтеп карыйк.

Әсәрне укуның темпы аның кайсы жанрга керүенә дә бәйле. Лирик әсәрне, мәсәлән, кызу-кызу укып булмый. Бу вакытта аның тәме, бөтен үзенчәлеге югала. Я менә бу шигырьне, такмак укыгандай, тиз-тиз ничек

укып булсын ди. Киресенчә, аны укыганда уйлану, моңлану, сагышлану өстенлек итәргә тиеш. Бу исә, үзеннән-үзе, укуның салмак-талгын агуын тәэмин итә.

Сөйләү темпының образ арактерына туры килүе сәнгатьлелекнең бер чарасы булып тора. Сөйләм темпын дөрес анлау һәм куллану авторның әйтергә теләгән төп фикерен җиткерүдә үтемле ярдәмче чара.

Сораулар һәм биремнәр

1.Басым, аның дәрәҗәләре, шартлы билгеләре.

2. Пауза, аның төрләре, үтәгән функцияләре.

3. Паузаның шартлы билгеләре.

4. Сөйләм темпы, аның сәнгатьле укуда әһәмияте

Тема 2.
ЛЕКЦИЯ 4. ИНВЕРСИЯ, ТАВЫШ, ЛОГИК ПЕРСПЕКТИВА.

Аннотация. Лекция барышында укучылар алдына сәнгатьле уку буенча таләпләр кую: гадилек һәм табигыйлек, әсәрнең фикри-сәнгатьчә эчтәлегенә үтеп керү, автор фикерләрен төгәл төшенү, укыла торган әсәргә үз мөнәсәбәтеңне белдерү, тыңлаучылар белән аралашу, сүзләрнең дөрес һәм төгәл әйтелешенә ирешү, үз тавышыңның диапазоны белән файдалана белү һәм аны киңәйтү, текстны ятлауның аеруча нәтиҗәле юлларын куллану. Тавыш, инверсия, логик перспектива турында фикерләр.

Ключевые слова: Сәнгатьле уку, тавыш, инверсия, логик перспектива.

Методик рекомендацияләр: Дәрестә теоритик мәсьәләләр карала. Әңгәмә рештырыла. Иҗади эш белән бәйле үрнәкләр тәкъдим ителә. Текстлар тикшерелә.

Төп әдәбият

1.Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: Таткитнәшр., 1988. - 86 б.
2.Галимуллин Ф.Г. Мәктәптә сәнгатьле уку: Студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: КДПИ, 1984. – 101 б.

3.Буяльский Б.А. Искусство выразительного чтения / Б.А. Буяльский. - М., 2006.
4.Майман Р.Р. Выразительное чтение. Практикум / Р.Р. Майман. - М., 2000.

Өстәмә әдәбият

5.Аксенов В.Н. Искусство художественного слова. - М., 2005.

6.Найденов Б.С. Выразительность речи и чтения. - М., 2000.

7.Рыбникова М.А. Очерки по методике выразительного чтения. - М., 2005.

Интернет ресурслар

http://studysphere.ru/work.php?id=339 - http://studysphere.ru/work.php?id=339

http://www.detskiysad.ru/ped/virazhenie.html - http://www.detskiysad.ru/ped/virazhenie.html

http://www.tatarstan.ru/books/ - http://www.tatarstan.ru/books/

Книгафонд - http://libress.kpfu.ru/wpad.dat
Книгафонд - www. knigafond.ru

Глоссарий

Диалог – кешеләрнең ике яклы аралашуын тәэмин итә торган берничә затның үз фикерен белдерүе, аралашуы. Лекция барышында сорау-җавап, яки, лектор тарафыннан гына кисәтү ясау һ.б. моментлар булырга мөмкин.

Жест – кешенең сөйләме, аралашуы барышында гомум моториканың (хәрәкәтнең) теге яки бу күләмдә чагылышы. Мисал өчен, мимика (бит-йөз мускулларының хәрәкәте), пантомимика – (бөтен гәүдәнең хәрәкәте) һәм жестикуляция (кул хәрәкәте).

Идея - әдәби әсәрнең идея-мәгънәви ягын белдерү өчен хезмәт итүче категория.

Интерпретация (шәрехләү) – текстның мәгънәсенә төшендерерлек итеп аңлату.

Сөйләм төгәллеге – фикерләрне ачык, аңлаешлы, дөрес җөмләләр белән ышандырырлык итеп җиткерү.

Сөйләм ритмы – басымлы һәм басымсыз авазларның, паузаларның чиратлашуы һ.б.

Инверсия. Татар теленең нык канунлашкан эчке закончалыклары бар. Шуларның берсе — җөмләдә иянең хәбәрдән алда килүе, сүз тезмәләрендә ияртүче сүзнең ияртүче сүздән элек урнашуы. Ләкин кайвакыт, тел кануннары чикләрен узып, сүзләрнең мондый тәртибен күпмедер дәрәҗәдә үзгәртергә дә мөмкин. Бу инверсия дип атала. Ә инверсияләнгән сүзләр, гадәттә, күрше сүзләрдән пауза белән аерылалар. Димәк, инверсия текст сүзләрен сөйләм тактларына бүлүдә өстәмә чара булып тора. Шунысын да әйтергә кирәк, инверсияләнгән сүз тыңлаучының игътибарын һәрвакыт үзенә тарта. (Мисаллар).

Инверсия куллану үзмаксат була алмый. Ул акланган булырга тиеш, көчле тойгы белән әйтелгән җөмләләрдә була. Шома гына барган текст хәтергә кереп калмаска мөмкин.

Тавыш. Еш кына укытучылар сәнгатьле уку дәресләрендә балалар алдына көчле тавыш белән һәм яңгыратып укуны таләп итеп куялар. Эмма, сәнгатьле укуда төп хикмәт тавышның көчле булуында түгел, бәлки укыган текстыңны тирән аңлап, аңа бөтен күңелеңне, барлыгыңны салуда. Кычкырып әйтү кешегә ул кадәр тәэсир ясамаска мөмкин, ә хисләнеп, яратып, нәфрәтләнеп әйтелгән сүз, тавыш көчәйтелеп әйтелмәсә дә, тыңлаучыга гаять үтемле булырга мөмкин.

Тавыш көченең шулай ук дәрәҗәләре дә була.

1. Пышылдау дәрәҗәсендә акрын.
2. Йомшак.
3. Уртача.
4. Көчле.
5. Бик көчле.

Сәнгатьле укучы бу диапозонны төрләндереп куллана белергә тиеш. Ягъни тавыш сыгылмалылыгы өстендә эшләү көндәлек шөгыль булып

әверелсен. Эсәрне тулысынча бер генә югарылыктагы тавыш белән укып чыксак, күңелсез булыр, тыңлаучының әһәмиятле фикерләргә игътибары туплана алмас иде. Мондый монотонлык эч пошу, ялыгу китереп чыгара, тыңлаучының әсәр белән кызыксынып китүен тәэмин итә алмый.

Укучының тавыш мөмкинлекләрен исәпләп, аңа репертуар сайларга булышу әдәбият укытучысының бер вазифасы. Чөнки әсәр укучы тавышының параметрларына туры килә икән, аны башкаруы да күпкә җайлы булачак. Бик кычкырып яки акрын уку да дөрес тугел.

Логик перспектива. Сөйләм җөмләләрдән тора. һәрбер җөмлә нинди дә булса бер фикерне белдерә. Болай караганда җөмләләр бер-береннән мөстәкыйль кебек. Ләкин чынлыкта алай түгел. 1 җөмләдә белдерелгән фикер икенчесендә ачыклана бара, аңа яңалары килеп өстәлә. Әнә шулай фикерләр тезмәсе барлыкка килә.

Бу җөмләләр бер-берсе белән мәгънә ягыннан бик нык керешеп киләләр. Гәрчә алар арасында нокталар куелса да, укыганда без ул нокталарны өтер, яки ноктaлы өтер куелгандай, фикернең дәвам ителәчәген белдерүче интонация белән укыйбыз, һәр җөмлә аерым-аерым укылса, текстның яңгырашы ямьсезләнер, андагы мәгънәне аңлау да күпкә кыенлашыр иде. Әгәр дә кеше, беренче җөмләне укыганда, алдагы җөмләләрдә сүз нәрсә турында барасын белмәсә, ул тиешле интонация сайлый алмый азаплана һәм шулай ук логик басымнарны да дөрес куя алмый. Чөнки аерым җөмлә белдергән фикер белән абзацтагы гомуми фикер арасында бераз аерма булуы да бик мөмкин.

Фикернең үзара бәйләнешен укыган вакытта дөрес бирү текстны тулаем логик перспектива белән укуны тәэмин итә. Гомуми эчтәлекне яхшы төшенү аерым җөмләләр белдергән фикерне тиешенчә яңгыратуга дөрес юл ача. Шуңа күрә без җөмләләрне аерып укымаска, ә бәлки үзара бәйләнешле интонация кулланып укырга тиешбез. Чөнки болар һәммәсе — текст бөтенлеген тәэмин итүче сәнгать чаралары. Логик перспективаны төгәл

билгеләү тыңлаучыга төп фикернең үсешен күзәтергә, аерым фразаларны һәм өзекләрне бербөтен текстның состав өлеше итеп кабул итәргә ярдәм итә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Тавыш, аның характеристикалары.
2. Логик перспективаны дөрес билгеләү ниләр белән бәйле?
3. Инверсияләнгән сүзләр җөмләдә ничек аерыла?
4. Текст сүзләрен сөйләм тактларына бүлүдә инверсиянең роле?

ЛЕКЦИЯ 5. Сөйләү техникасы. Сулыш.

Аннотация. Дәрес барышында дөрес сулыш алуның сәнгатьле укудагы роле, сулышның ике төрле булуы ачыклана. Моның өчен күнегүләр тәкъдим ителә.

Ключевые слова: Сулыш, сөйләм аппараты, күнегү.

Методик рекомендацияләр: Дәресләр дөрес сулыш алу һәм артикуляция күнекмәләре булдырудан башлана. Студентларның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып, теге яки бу махсус күнегүләр тәкъдим ителә һәм болар укытучы күзәтүе астында үткәрелә. Дәресләрне уздыруның темаларын һәм юнәлешләрен укытучы, аерым шартлардан чыгып, үзгәртергә һәм баетырга мәмкин. Мәсәлән, группа белән дәрес, бер-берсенең укуына бәя бирү, уңай һәм кимчелекле якларын табу. Сәнгать осталары белән очрашулар, магнитафон язмасыннан һәм грампластинкалардан күренекле артистлар башкаруында әдәби әсәрләр тыңлау, спектакльләргә, әдәби концертларга бару да булырга мөмкин.

Төп әдәбият

1. Асылгараев Ш.Н. Сәнгатьле уку буенча практикум. / Ш.Н.Асылгараев. - Казан: КДПИ, 1973.
1. Галимуллин Ф.Г. Мәктәптә сәнгатьле уку: Студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы. / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: КДПИ, 1984. – 101 б.

2. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма. / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: Таткитнәшр., 1988. - 86 б.

Өстәмә әдәбият

1.Аксенов В. Искусство художественного слова. / В.Аксенов. - М.: Учпедгиз., 1962.
2. Артоболевский Г.В. Художественное чтение. / Г.В. Артоболевский. - М.: Просвещение, 1978.

Интернет ресурслар

http://www.tatarstan.ru/books/ - http://www.tatarstan.ru/books/

Книгафонд - http://libress.kpfu.ru/wpad.dat
Книгафонд - www. knigafond.ru

Глоссарий

Диалект – теге яки бу як, төркем кешеләренә сөйләшенә генә хас сүзләр, җөмләләр һ.б.

Диалог – кешеләрнең ике яклы аралашуын тәэмин итә торган берничә затның үз фикерен белдерүе, аралашуы. Лекция барышында сорау-җавап, яки, лектор тарафыннан гына кисәтү ясау һ.б. моментлар булырга мөмкин.

Комментария – лектор тарафыннан теге яки бу мәсьәләгә ачыклык кертү.

Конкретлаштыру – композицион-стилистик алым, теге яки бу мәсьәләгә ачыклык кертү өчен аны детальләштерү.

Лекция-беседа – тыңлап утыручыларның да актив катнашуын таләп иткән чыгыш-лекция .

Гадәттә, сөйләү аппараты дигәндә, сулыш алу органнарын: үпкәләр, диафрагма, кабыргалар, тамак, тавыш ярыларын, йоткылыкны, борын, авыз, тел, тешләр, иреннәр, кече тел, тагын башка органнарны күз алдына килә. Чөнки нәкъ шушы органнар сөйләүдә аеруча актив катнашалар. Ләкин сөйләү бик катлаулы күренеш. Бу процесс вакытында, телисеңме-теләмисеңме, бөтен организм катнаша.

Сөйләү вакытында аеруча актив катнашучы органнар арасында аеруча әһәмиятлесе - үпкә. Бу урында дөрес сулыш алу турында сүз алып барырга туры килә.

Сулыш ике төрле була: аскы һәм өске сулыш. Өске сулыш булганда үпкәнең өске өлеше генә һава белән тутырыла. Димәк, бу кешенең организмын кислород белән тәэмин итүдә үпкәнең бөтен өлеше дә катнашмый.

Аскы сулыш алу төрле яклап файдалы. Бу вакытта үпкәнең бөтен җире дә, кабыргалар да хәрәкәткә килә.

(Сулышны борын аша, чәчәк иснәгән кебек алырга кирәк. Үпкәгә һаваны тыгызлап ук тутырырга киңәш ителми. Алган һава беткәч тә, әйтәсе сүзне әйтеп бетерәм дип, азаплану шулай ук зыянлы).

Тавыш ярыларына беркайчан да көч китермәскә тырышыгыз

Сулыш юллары тәртиптә булсын һәм, әлбәттә, борын аша иркен сулый белергә кирәк. Борын аша үткәндә һава чистара, дымлана һәм җылына Әгәр борын аша сулау кыенлашса, врач-отолоринголог ярдәмендә аның сәбәбен ачыкларга һәм дәваларга кирәк. Авырганда (катар, ангина яки тамак ялкынсынганда) тавышка көч китерергә, бигрәк тә лекция, доклад сөйләргә, җырларга ярамый.

Бугаз салкын тиюләргә бирешмәсен өчен, организмны чыныктырырга кирәк. Исерткеч эчемлек, артык әче яки тозлы ризык, тәмәке тарту да зарарлы. Тәмәке төтене авызның, йоткылыкның, бугазның, бронхларның лайлалы тышчасын ялкынсындыра, селәгәйнең кирәгеннән артык бүленеп чыгуына китерә. Тәмәке тартучы кеше әллә кайдан беленеп тора, аның тавышы карлыккан, ямьсез булыр.

Сәнгатьле уку вакытында үпкәдә һәрвакыт ниндидер күләмдә һава запасы булырга тиеш. Моның өчен махсус күнегүләр үткәрү, ничек сулыш алуына даими игътибарлы булу кирәк. Бу турыда Ш. Асылгәрәевнең «Сәнгатьле уку буенча практикум» дигән ярдәмлегендә, мәсәлән, түбәндәге күнегүләр тәкъдим ителә:

1 нче күнегү.

Чалкан яткан хәлдә кулыгызны эчегезгә куегыз һәм тыныч кына сулагыз. Сулыш алганда кулыгызның күтәрелүен, сулыш чыгарганда төшүен тоярсыз. Әгәр диафрагманың хәрәкәте бөтенләй тоелмаса яки сизелер-сизелмәс кенә булса, аны активлаштыру таләп ителә. Моның өчен п-ф-ф дип үпкәдәге һаваны мәҗбүри рәвештә этеп чыгарырга кирәк. Бу хәрәкәтне ныгыту һәм беркетү өчен күнегү 3—4 мәртәбә кабатлана. Шуны истә тоту хәерле: сулыш чыгару сулыш алуга караганда һәрвакыт озын була. Сулыш алу «бер-ике» дигәндә башкарылса, сулыш чыгару «бер, ике, өч, ДҮрт»тә үтәлә. Бу күнегүне берничә көн дәвамында көненә ике тапкыр (иртә, кич) ясарга тәкъдим ителә. Билгеле, ул чалкан яткан хәлдә генә түгел, аякларга туры басып торган хәлдә дә үтәлергә тиеш.

Диафрагманың хәрәкәтен тою өчен уң кулыгызны эчегезгә, сулын түбән кабыргаларга куегыз. Диафрагманы механик рәвештә, мускул көче белән хәрәкәткә китерү тыела. Күнегүне сулыш чыгарудан башлагыз. Һава алу ихтыяҗы тусын өчен бер секунд чамасы пауза ясагыз Күнегүләрне шул рәвешле башкарганда диафрагманың хәрәкәте табигый булыр.

2 нче күнегү.

Иркен һәм тыныч хәлдә торуыгызга ышангач, п-ф-ф.л дип сулышыгызны чыгарыгыз.Сулыш тигез булырга Һәм идарә ителергә тиеш. Үпкәләрдәге һаваны чыгару өчен сарыф ителә торган көч тә даими булсын, һава запасын баштан ук күп итеп чыгармаска, ягъни сулыш мускулларына бушанырга ирек бирмәскә кирәк. Сулыш чыгару өчен өстәмә көч таләп ителсә, һава чыгару процессын туктатыгыз. Яңадан һава алырга ашыкмагыз. Сулыш алгач (борын аркылы), бер секунд чамасы пауза ясагыз, шуннан сон тагын п-ф-ф-ф дип сулышыгызны чыгарыгыз.

3 нче күнегү.

П-ф-ф-ф дип сулышыгызны чыгарыгыз. Ә үпкәләргә һава алу бердән бишкә кадәр санауга киткән вакыт берәмлеге озынлыгында булырга тиеш. Бу вакытта бердән өчкә кадәр булган вакыт берәмлеге диафрагмаларның, дүртенчесе — кабыргалар киңәюе, бишенчесе — эч мускулларының эшчәнлек катнашы хисабына сарыф ителә. Бер секунд чамасы паузадан соң тагын п-ф-ф-ф дип сулышыгызны чыгарыгыз. Үпкәләргә һаваны күп алырга тырышмагыз, сулыш алу тигез, салмак булырга тиеш. Сулыш схемасы болай була:

а) п-ф-ф-ф дип сулыш чыгару;

б) пауза;

в) сулыш алу: 1—2—3—диафрагма белән, 4—кабырга яисә кабырга аралыгы мускуллары белән, 5— эч мускуллары белән;

г) тоткарлану;

д) п-ф-ф-ф дип сулыш чыгару.

Диафрагма сезнең ихтыярга буйсынмаса, 1 нче күнегүдә тәкъдим ителгән алым ярдәмендә аны күнектерегез. Кабырга һәм кабырга аралыгы мускулларын да махсус хәрәкәтләр ясап күнектерергә була. Моның өчен дүрт бармакны алга, баш бармакны артка каратып, түбән кабыргаларны кулларыгыз белән кысыгыз. Сулыш алганда уч төбегез күкрәк читлегенең киңәюен тойсын.

Чыныктыру һәм беркетү өчен түбәндәге күнегүләр тәкъдим ителә:

А) п-ф-ф-Ф Дип сулыш чыгарыгыз, аннан соң диафрагма кабырга аралыгы мускуллары катнашы белән «бер-ике» мәртәбә генә сулыш алыгыз, «өч-дүрт» дигәндә пауза алыгыз, «биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун» дигәндә сулыгыгызны чыгарыгыз. Күнегүне ике тапкыр кабатлагыз. Үзең түгел, бәлки икенче берәү алып барса яхшырак.

б) эч мускулларының ничек эшләвен тою өчен кулыгызны эчегезнең аскы өлешенә куегыз һәм йөткерегез. Шул вакытта эч мускулларының кыскаруына игътибар итегез. Бу кыскару сулыш чыгару алдыннан ясала торган тоткарлану

вакытында була.

в) п-ф-ф-ф дип сулыш чыгарыгыз да, тиз генә сулыш алыгыз һәм һаваны кыска гына вакытка тоткарлагыз. Шуннан соң бердән унга кадәр санагыз. Санау процессында сулыш алу булмасын, ягъни сүз аралыгындагы паузаларда сулыш органнары хәрәкәтсез калырга тиеш.

Күнегүләр нәтиҗәсендә һава запасы калса, «унбер, уникe» һ. б. дип санауны дәвам итегез. Ләкин санау өчен генә өстәмә көч сарыф ителмәсен һәм темп тизләтелмәсен.

5 нче күнегү.

Кул хәрәкәтләре ярдәмендә сулыш күнегүләре башкарыгыз. Сулыш алу һәм сулыш чыгару фәкать кул хәрәкәтләре вакытында гына булырга тиеш.

Кулларны алга сузганда сулышыгызны тышка чыгарыгыз, як-якка җибәргәндә эчкә алыгыз, ян-яктан аска төшергәндә тышка чыгарыгыз, баш өстенә күтәргәндә эчкә алыгыз. Бу күнегүне биш мәртәбә кабатларга кирәк. Ләкин шуны истән чыгармагыз: сулыш чыгару сулыш алуга караганда 2—3 тапкыр озынрак була.

Мондый күнегүне ясаганда, гәүдә төз булырга, аякларда иркен генә басып торырга кирәк. Мускулларда көчәнү булмаска тиеш. Уң кулны эчкә, сулын кабыргаларга куегыз. Бу юл белән диафрагма һәм кабыргаларның сулыш алу процессында катнашуын контрольдә тотабыз. Күнегүләрне саф һавалы бүлмәдә ясарга кирәк. Форточка -яки тәрәзә ачык булсын. Күнегү сулышны чыгару белән башлана.

Аннан аз гына тукталыш. 1—2 дигәнче тирән итеп сулыш алына. 1—2 дип санап сулыш тотып торыла. 1—2 дигәнче сулыш чыгарыла. Баштагы күнегүләрдә сулыш алунын, өч циклы да бер үк дәвамлылыкта башкарыла. Таблицадан күренгәнчә, тора-бара сулыш алу һәм аны чыгару

вакытының дәвамлылыгы арта бара, сулышны чыгару вакытының дәвамлылыгы тагы да зуррак була.

Баштарак сулышны чыгарганда «с» авазын әйтеп торырга кирәк. Бу сулыш чыгаруның тигезлеген белергә ярдәм итә. «с» авазының ишетелеше көчәйсә яки кимесә, һава тигез чыкмый дигән сүз. Моны тиз генә тиешле дәрәҗәгә көйләргә була. Баш җиңелчә әйләнә башласа, күнегүне туктатырга туры килә.

Дөрес сулыш алу сәнгатьле укуда бик әһәмиятле. Ләкин аның әһәмияте моның белән генә бетми әле. Гадәти дәрес материалын аңлатканда да без һәрвакыт сөйләмебезнең камил, матур, дөрес булуы турында кайгыртырга тиешбез. Моңа дөрес сулыш алу, тавышны рациональ файдалану нәтиҗәсендә генә ирешелә.

Сораулар һәм биремнәр

1.Урта мәктәп дәресләрендә сәнгатьле укырга тәкъдим ителгән әсәрләр өстендә эшләү үзенчәлекләре.
2. Сулыш. Катнаш сулыш алу.
3. Сөйләм темпы, аның сәнгатьле укуда әһәмияте.
4. Сөйләм темпының төрләре, әсәрнең төп фикерен җиткерүдә аның әһәмияте.

ГЛОССАРИЙ

Анализ (бүлгәләү) – бербөтенне өлешләргә таркатып, төп кисәк-компонентларны аерып чыгаручф һәм алар арасындагы бәйләнешләрне табучы фәнни ысул.

Антитеза – капма-каршы төшенчәләрне, факт, образларны махсус рәвештә капма-каршы кую.

Антонимнар – капма-каршы мәгънәдәге сүзләр.

Аргументы – лекция уку барышында лектор тарафыннан ышандыру өчен кулланылган психологик, логик и фактик дәлилләр (идея, чакыру, мисал, фактлар һ.б.) һәм аларны куллану ысуллары.

Нәтиҗә – лекция азагында сөйләгәннәрне йомгаклап кую, нәтиҗә ясау.

Диалект – теге яки бу як, төркем кешеләренә сөйләшенә генә хас сүзләр, җөмләләр һ.б.

Диалог – кешеләрнең ике яклы аралашуын тәэмин итә торган берничә затның үз фикерен белдерүе, аралашуы. Лекция барышында сорау-җавап, яки, лектор тарафыннан гына кисәтү ясау һ.б. моментлар булырга мөмкин.

Жест – кешенең сөйләме, аралашуы барышында гомум моториканың (хәрәкәтнең) теге яки бу күләмдә чагылышы. Мисал өчен, мимика (бит-йөз мускулларының хәрәкәте), пантомимика – (бөтен гәүдәнең хәрәкәте) һәм жестикуляция (кул хәрәкәте).

Идея - әдәби әсәрнең идея-мәгънәви ягын белдерү өчен хезмәт итүче категория.

Интерпретация (шәрехләү) – текстның мәгънәсенә төшендерерлек итеп аңлату.

Импровизация – алдан әзерлексез башкарылган гамәл.

Интонация – мәгънәви, синтаксик, эмоциональ-экспрессив функция башкаручы ритмлы-мелодик сөйләм сыйфаты. Ул үз эченә түбәндәге элементларны ала: мелодия, темп, ритм, сөйләм көче, тавыш тембры, шулай ук мәгънәви, фраза, логик басым һ.б.

Интонацион шигырь – буыннар төшеп калу яки өстәлү сәбәпле, төрле ритмик үлчәмдә язылган шигырь формасы.

Комментария – лектор тарафыннан теге яки бу мәсьәләгә ачыклык кертү.

Конкретлаштыру – композицион-стилистик алым, теге яки бу мәсьәләгә ачыклык кертү өчен аны детальләштерү.

Лекция-беседа – тыңлап утыручыларның да актив катнашуын таләп иткән чыгыш-лекция .

Логик пауза – әһәмиятле пауза, текстны төгәл, дөрес итеп уку өчен, мәгънәле кисәкләрне аерып чыгару өчен кулланыла.

Логик басым – җөмләдәге бик әһәмиятле сүзне яки сүзтезмәне аерып чыгару өчен тавышны күтәрү юлы белән күрсәтелә.

Сөйләм мелодиясе – сөйләм барышында тавышны яки күтәрү, яки төшерү юлы белән күрсәтелә.

Метафора – бер предметның сыйфатын башкасына күчереп кую.

Монолог– бер генә кешенең сөйләме, яки, тыңлаучыларга мөрәҗәгате.

Омонимы – бер үк яңгырашлы, әмма, мәгънәләре туры килмәгән сүзләр.

Пауза – физиологик, грамматик, психологик яки логик факторлар белән бәйле рәвештә сөйләмдә туктап тору.

Сөйләмдә пафос – сөйләмдә эмоциональлек, стилистик күтәрелеш, интонациядә, манерада сәнгатьлелек.

План – сөйләмнең эзлеклелеге, үзәк мәсьәләләрнең кыска гына бирелеше.

Сөйләм ритмы – басымлы һәм басымсыз авазларның, паузаларның чиратлашуы һ.б.

Стиль - тар мәгнәсендә язучының тормыш тәҗрибәсеннән, яшәешне аңлау дәрәҗәсе, фикерләү рәвешеннән килеп чыга торган һәм әсәрләрнең тематикасында, сюжет-композициясендә, образлы телендә чагылучы индивидуаль әдәби алымнар системасы.

Сөйләм тембры – авазлар бизәге.

Сөйләм темпы – сөйләм барышында авазларны, сүзләрне, җөмләләрне әйтү тизлеге.

Сөйләм төгәллеге – фикерләрне ачык, аңлаешлы, дөрес җөмләләр белән ышандырырлык итеп җиткерү.

ӘДӘБИЯТ

1. Аксенов В. Искусство художественного слова. / В.Аксенов. - М.: Учпедгиз., 1962.
2. Артоболевский Г.В. Художественное чтение. / Г.В. Артоболевский. - М.: Просвещение, 1978.
3. Асылгараев Ш.Н. Сәнгатьле уку буенча практикум. / Ш.Н.Асылгараев. - Казан: КДПИ, 1973.
4. Галимуллин Ф.Г. Мәктәптә сәнгатьле уку: Студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы. / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: КДПИ, 1984. – 101 б.

5. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма. / Ф.Г. Галимуллин. - Казан: Таткитнәшр., 1988. - 86 б.
6. Горбушина Л.А., Николаичева А.П. Выразительное чтение. / Л.А.Горбушина, А.П.Николаичева. - М.: Просвещение, 1978.
Методика выразительного чтения / Общ. Ред. Т.Ф.Завадской, Н.М. Соловьевой. М.: Просвещение. – 1985. –208 с.
7.Нигъматуллин Ә. Сәнгатьле укырга өйрәник. / Ә.Нигъматуллин. - Казан: Таткитнәшр. – 1968. –174 б.
8.Сәлимҗанов Х. Нәфис сүз. / Х. Сәлимҗанов. - Казан.: Таткитнәшр. – 1958. – 84 б.
9.Соловьева Н.М. Практикум по выразительному чтению. / Н.М.Соловьева. - М.: Прсвещение. – 1976.
10. Хәйруллина А. Дөрес сөйләргә өйрәнегез. / А.Хәйруллина. - Казан: «Казан» нәшрияты. – 1962. –96 б.
11. Хәйруллина А. Тел күрке – сүз. / А.Хәйруллина. – Казан: Таткитнәшр. – 1978.

Мөстәкыйль эш өчен биремнәр һәм контроль сораулар

1. Сәнгатьле укуның туган тел һәм әдәбиятны укытудагы әһәмиятен нәрсәдә күрәсез?
2. Мәктәптәге сәнгатьле уку белән олы сәнгатьтәге сәнгатьле уку арасында нинди аермалар бар.
3. Укучының үз сөйләмен аһәңле, үтемле итеп эверелдерүдә сәнгатьле укуның ярдәмениләрдән гыйбарәт?
4. Язма текстны яңгыраучы текстка әвәрелдергәндә кеше нинди бурычларны хәл итә?
5. Әдәби әсәр текстын үз сүзең итеп эверелдерү дигәндә,ниләрне күздә тотабыз һәм моны ничек эшлибез?
6. Сөйләм культурасы белән сәнгатьле уку арасында нинди аерма бар?
7. Сүзне әйтү максаты белән тиешле интонация арасындагы бәйләнешне ниләрдә күрәбез?
8. Интонациянең төгәл яңгыравының нигезендә ниләр ята?
9. «Тел төбен» (подтекстны) дөрес билгеләү ниләр белән бәйле?
10. “Тел төбен” (подтекстны) дөрес билгеләү белән тиешле интонацияне табудагы бәйләнешләр турында ниләр әйтә аласыз?
11. “Тел төбен” (подтекстны) белдерү чараларыннан дөрес файдалануның әһәмиятен сез ниләрдә күрәсез?
12. Тел дәресләрендә сәнгатьле укуның үзенчәлекләре нидән гыйбрәт?
13. Әдәбият дәресләрендә сәнгатьле укуның үзенчәлекләре ниләрдән гыйбарәт?
14. Укыласы әсәрнең партитурасын төзүгә куела торган таләпләр турында сез ниләр беләсез?
15. Лирик әсәрне сәнгатьле уку үзенчәлекләре ниләрдән гыйбарәт?

16. Патетик әсәрне сәнгатьле уку үзенчәлекләре niләрдән гыйбарәт?
17. Сатира һәм юмор әсәрен сәнгатьле уку үзенчәлекләре niләрдән гыйбарәт?
18. Шигъри әсәрне сәнгатьле уку үзенчәлекләре niләрдән гыйбарәт?
19. Проза әсәрен сәнгатьле уку үзенчәлекләре niләрдән гыйбарәт?
20. Мәсәлне сәнгатьле уку үзенчәлекләре niләрдән гыйбарәт?
21. Көйләп укуның сәнгатьле укуга ирешүдә комачау итүен сез niләрдә күрәсез?
22. Әдәби әсәрне ятлауның иң отышлы алымнарыннан сез кайсысын ешрак кулланасыз һәм ни өчен?
23. Укучыларның сәнгатьле укуларын тикшерүнең кайсы алымнарын иң нәтиҗәлерәк дип саныйсыз һәм ни өчен?

Гамәли сораулар

1. Г.Тукайның «Туган тел» шигыренең текстыннан басымлы (мәгънәви, тойгылы) сүзләрне билгеләргә.
2. М.Җәлилнең «Дару» шигыренең текстына паузалар (мәгънәви, тойгылы) билгеләргә.
3. Ф.Кәримнең «Ант» шигыренә сөйләм темпын билгеләп чыгарга.
4. Һ.Такташның «Мокамай» шигырендә тавыш көченең үзгәрешләрен билгеләп чогарга.
5. Х.Туфанның «Иртәләр җитте исә» шигырен укыгандагы хисләр алмашуның үсешен эзлекле билгеләргә.
6. Р.Харисның «Ак сөлге» шигыренең төп фикерен билгеләргә һәм аның әсәр тукымасындагы эзлекле үстерелешен күзәтергә.
7. С.Хәкимнең «Юксыну» шигыренең музыкальлек сыйфатларын билгеләгез, аның шигырьне укуга тәэсирен ачыклагыз.
8. М.Җәлилнең «Җырларым» шигыренә партитура төзегез.
9. Г.Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәренең «Башлангыч» дигән өлешенә партитура төзегез.
10. Г.Кутуйның «Сагыну» нәсеренә партитура төзегез.

Зачет өчен сораулар

1. Әдәбият дәресләрендә сәнгатьле укуның әһәмияте .
2. Нәрсә ул сәнгатьле уку? Аңа куелган таләпләр.
3. Метод һәм алым буларак әдәбият дәресләрендә сәнгатьле уку. Аңа куелган таләпләр.
4. Сәнгатьле укуга багышланган фәнни-методик хезмәтләргә күзәтү.
5. Күтәрелмә интонация.
6. Төшерелмә интонация.

7. Сәнгатьле укуның сөйләм культурасын үстерүдәге әһәмияте.
8. Дәрестә әдәби әсәрне эмоциональ анализлауда сәнгатьле укуның роле.
9. Текстны перспектива белән уку, сез аны ничек аңлыйсыз?
10. Интонация. Аның төрләре.
11. Сәнгатьле укуга әзерләнгәндә әдәби әсәрне анализлау, аның тәртибе.
12. Тулы һәм катнаш интонацияләр турында сөйләргә.
13. Укучылар алдына сәнгатьле уку буенча куела торган төп таләпләрне аңлатып бирергә.
14. Тавыш, аның характеристикалары. Балаларның тавышын саклау һәм үстерү юллары.
15. Мәктәптә әдәбият дәресләрендә сәнгатьле укырга өйрәтүдә техник чараларны файдалану, аның әһәмияте.
16. Подтекстны (тел төбен) белдерү чаралары, аларның төрләре, бурычлары.
17. Дәрестә күмәк укуны оештыру методикасы.
18. Басым, аның дәрәҗәләре, шартлы билгеләре.
19. Пауза, аның төрләре, үтәгән функцияләре.
20. Басым, аның дәрәҗәләре, шартлы билгеләре.
21. Урта мәктәп дәресләрендә сәнгатьле укырга тәкъдим ителгән әсәрләр өстендә эшләү үзенчәлекләре.
22. Сулыш. Катнаш сулыш алу.
23. Сөйләм темпы, аның сәнгатьле укуда әһәмияте.
24. Сөйләм темпының төрләре, әсәрнең төп фикерен җиткерүдә аның әһәмияте.
25. Нәсерне сәнгатьле уку үзенчәлекләре.
26. Драма әсәрен рольләргә бүлеп уку методикасы.